# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**26.03.2024** **№ 1**

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Девәтернә торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында» 21.11.2023 елның 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Девәтернә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 21.11.2023 елның 1 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 26 мартындагы узган гражданнарның җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Девәтернә торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында» 21.11.2023 елның 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбуладагы түбәндәге «- МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү (запас частьләр сатып алу, дизель ягулыгы һәм май сатып алу; килешү буенча тракторчының эшләре өчен түләү);

- Девәтернә торак пунктында яктырту өчен лампалар, дроссельләр, фонарьлар сатып алу, урнаштыру; шартнамә буенча электрик эшләре өчен түләү;
- халыкны су белән тәэмин итү (ремонт, хезмәт күрсәтү, тирәнлек насослары һәм материаллар сатып алу һәм торак пунктта су белән тәэмин итү өчен башка хезмәтләр);
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, автозапчастьлар сатып алу, янгын сүндерү машинасы йөртүчесенә хезмәт килешүе буенча түләү);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Ленин урамы юллары өчен вак таш сатып алу һәм җәю; Девәтернә торак пункты урамнарны кардан чистарту);
- Девәтернә торак пунктын төзекләндерү (үлән һәм чүп үләннәрен чабу;);
- Бөек Ватан сугышында катнашучыларга куелган һәйкәлне ремонтлау;
- Девәтернә торак пунктында авария хәлендәге һәм коры үсентеләрне кисү.» сүзләрен

«1) торак пункт территориясен төзекләндерү (авария хәлендәге һәм коры усентеләрне кисү, үлән һәм чүп үләннәрен чаптыру, юлларны кардан чистарту, тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, трактор өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, тракторчыга хезмәт килешүе буенча түләү һәм торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар);

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Ленин урамы юллары өчен вак таш сатып алу һәм җәю; урамнарны кардан чистарту);

3) су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аларны чистарту, транспортировкалау һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын ремонтлау, (сантехник һәм чыгым материалларын, тирәнлек насослары сатып алу һәм торак пунктта су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар);

4) урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау (лампалар, дроссельләр, фонарьлар сатып алу һәм алыштыру; урам яктырту буенча башка чыгымнар);

5) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасы йөртүчесенә хезмәт шартнамәсе буенча түләү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар);

6) һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәйкәл ясау һәм урнаштыру).» сүзләренә алмаштырырга.

2) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (авария хәлендәге һәм коры усентеләрне кисү, үлән һәм чүп үләннәрен чаптыру, юлларны кардан чистарту, тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, трактор өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, тракторчыга хезмәт килешүе буенча түләү һәм торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар);

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Ленин урамы юллары өчен вак таш сатып алу һәм җәю; урамнарны кардан чистарту);

3) су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аларны чистарту, транспортировкалау һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка

инженерлык корылмаларын ремонтлау, (сантехник һәм чыгым материалларын, тирәнлек насослары сатып алу һәм торак пунктта су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар);

4) урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау (лампалар, дроссельләр, фонарьлар сатып алу һәм алыштыру; урам яктырту буенча башка чыгымнар);

5) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасы йөртүчесенә хезмәт шартнамәсе буенча түләү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар);

6) һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәйкәл ясау һәм урнаштыру).»

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында https://agryz.tatarstan.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Девәтернә авыл җирлеге башлыгы Э.Э.Ганиев